ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь 2026ел № 6231

Сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу шартнамәсе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир участоклары бәясен билгеләү тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пункт, 39.4 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге яки дәүләт милке чикләнмәгән, биналар, корылмалар урнашкан җир участокларын мондый биналарның, корылмаларның яисә алардагы бүлмәләрнең милекчеләренә сату турында» 2012 елның 3 октябрендәге 827 номерлы Карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу шартнамәсе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир участоклары бәясен билгеләү тәртибен кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

1) «Сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир участокларын сату бәясен билгеләү тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 1 ноябрендәге 6671 номерлы;

2) «Башкарма комитетның 2017 елның 1 ноябрендәге 6671 номерлы Карары белән расланган сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир участокларын сату бәясен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 14 гыйнварындагы 71 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 23 июнендәге
6231 номерлы карарына
кушымта

Сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу шартнамәсе төзегәндә,
Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан
җир участоклары бәясен билгеләү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 1.1, 3, 6, 7, һәм 10 пунктчалары нигезендә, сатулар үткәрмичә җир участогын сату-алу шартнамәсе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир участоклары бәясен билгели.

2. Базар бәясенә тигез, ләкин җир участогының кадастр бәясеннән артмаган бәя белән сату гамәлгә ашырыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү, үстерү максатларында «Торак төзелешен үстерүгә, туристлык инфраструктурасы объектларын булдыруга һәм территорияләрне башкача үстерүгә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән аренда шартнамәсе яки түләүсез файдалану шартнамәсе буенча бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын;

2) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә, мондый ширкәт әгъзасына бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән бакча җир участогын яки яшелчә җир участогын;

3), юридик затларның даими (срогы чикләнмәгән) файдалануында булган җир участокларын (әлеге җир участокларында биналар, корылмалар булмаган очракта) күрсәтелгән юридик затларга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш;

4) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 5 пунктында каралган очракларда, җир участокларын гражданнарга индивидуаль торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару өчен.

3. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда, биналар, корылмалар урнашкан җир участокларын мондый биналарның, корылмаларның яисә алардагы бүлмәләрнең милекчеләренә саткан очракта, җир участогының бәясе шундый җир участогында урнашкан бина, корылма яисә алардагы биналарның милекчесе мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдә булган җир участогының кадастр бәясенең 25 процентын тәшкил итә.

4. Биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең яисә алардагы бүлмәләрнең милекчеләре түбәндәге очракларда аренда хокукында аларда булган җир участокларын җир участогының кадастр бәясенең 2,5 процентына тигез бәядән милеккә сатып алалар, әгәр:

1) «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән башлап 2012 елның 1 июленә кадәр күрсәтелгән җир участокларына карата даими (срогы

чикләнмәгән) файдалану хокукын аренда хокукына яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылган;

2) күрсәтелгән җир участоклары «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән башлап 2012 елның 1 июленә кадәр аларга карата даими (срогы чикләнмәгән) файдалану хокукын аренда хокукына яңадан рәсмиләштерү гамәлгә ашырылган җир участокларыннан барлыкка килгән.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева